| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ**<br>**БЕРӘМЛЕГЕ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.11.2024** **№14**

2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразы турында

«2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025-2026 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Ә.Мөхәмәдиева

1 нче кушымта

**2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең**
**социаль-икътисадый үсеш фаразы**

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 761 | 765 | 781 | 769 | 750 | 750 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Эре мөгезле терлекләр саны | баш | 481 | 482 | 483 | 485 | 432 | 432 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Инвестицияләр | мең сум. | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Торак тапшыру | кв. м. | 50 | 50 | 50 | 60 | 60 | 50 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Хезмәт өчен түләү фонды | мең сум. | 15140,2 | 16654,2 | 17836,6 | 19120,8 | 20516,6 | 22110,9 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум. | 43506,3 | 47856,9 | 52254,6 | 54944,8 | 58955,7 | 62955,7 |
| Хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны | кеше | 29 | 29,00 | 29,00 | 29,00 | 29,00 | 29,00 |
| Эшмәкәрләр саны (КФХ)) | кеше | 13 | 13 | 13 | 14 | 14 | 14 |
| Эшсезләр саны | кеше | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

**2024 елга һәм 2025-2026 елларның план чорына
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге
социаль-икътисадый үсеш фаразына
аңлатма язуы**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнары статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең 2024-2026 еллар чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән 2024-2026 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең 2024 елда көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2025-2026 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, 2024-2026 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм дефлятор-индексларны кулланып эшләнде.

2025-2026 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 85 АКШ доллар дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2024 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 90,1 сум, 2025 елда –91,1сум дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана. 2026 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 92,3 сум тәшкил итәчәк.

Янурыс авыл җирлеге өч торак пункттан тора: Янурыс, Каташ Каран һәм Иске Әхмәт авыллары.

Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең 2024 елга халык саны 750 кеше тәшкил итәчәк, 2025 елга-748 кеше, 2026 елга-749 кеше.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның булган потенциалын һәм үсеш тенденцияләрен, шулай ук «Развитие АПК» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, «АГРОСИЛА ГРУПП» Мөхәммәдиев Ф.Н, Абдулаев М.Т.Сәлимов Т.А. крестьян-фермер хуҗалыклары эшчәнлеге алып барыла.

2024 ел бәяләве буенча эшмәкәрләр саны 13 кеше тәшкил итәчәк, 2025 елга-14 кеше, 2026 елга-14 кеше.